ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 июнь 2016 г. № 3381

Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 29 июлендәге 4296 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәттән файдалану урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин итедә | |

| | | |
|---|---|---|
| тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларда хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып. | |

2) кушымтаны (белешмәне) кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Э.Ф. Тимергалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 30 июнендәге
3381 номерлы карарына
кушымта

Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Rinat.Abdullin@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | Eldar.Timergaliev@tatar.ru |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева